

# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Кугәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№1 Сентябрь 2024 ел*

## Ветеран укытучыларыбыз белән танышуны дәвам итәбез



**Борһанова Земфира Гиният кызы**

1944 елның 9 сентябрендә Буа районы Иске Тинчәле авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә.

1960 нчы елны сигезьеллык мәктәпне тәмамлый.

1963 нче елда КГПИның “Естественно-географический” факультетының химия -биология бүлегенә укырга керә.

1965 нче елны Арча районы Кугәм сигезьеллык мәктәбенә химия-биология фәне буенча укытырга кайта.

Земфира Гиният кызы 1965 нче елдан 1976 нчы елга кадәр укытучы һәм мәктәп яны тәҗрибә участогы мөдире булып эшли, күп кенә мактау грамоталары белән бүләкләнә:

1973 ел - ТАССР мәгариф министрлыгы һәм Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждение хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан өлкә комитеты Почет грамотасы;

1975 ел - ТИУУның Почет грамотасы;

1984 ел- Арча РОНОсы һәм райком профсоюзы тарафыннан Почет грамотасы;

1994 ел - Әтнә район мәгариф бүлеге тарафыннан Почет грамотасы.

1994 ел - Россия Федерациясенең мәгариф министрлыгының ”Отличник народного просвещения ” күкрәк значогы;

1999 ел - фидакарь хезмәте өчен Татарстан мәгариф министрлы-гының Мактау кәгазе;

2019 ел - Татарстан мәгариф министрлыгының Рәхмәт хаты.

**Сөнгатова Гөлнара, тарих укытучысы**

## Җәйге хезмәт чиреге.



Җәйге каникул чорында мин әтием белән Әтнә кумәк хуҗалыгында, комбайнер ярдәмчесе булып “Класс Тукано – 430” комбайнында эшләдем. Комбайнда эшләү дәверендә мин әтиемнән бик күп эшләргә өйрәндем. Эшләгән вакытта куана - куана узыштан эшләгән вакытлар да, ватылып алган вакытлар да булды. Ләкин без тиз вакытта төзәтеп эшебезне дәвам итә идек.

Баштарак комбайнның тәрәзәләрен юарга өйрәндем, ә соңыннан әтием белән комбайнны төзәтергә дә өйрәндем. Әтинең ярдәмчесе булып беттем! Иң авыры комбайнда, аның бункерына төшеп чистарту иде, әтием ярдәме белән ансын да эшләргә өйрәндем.

Шушы басуда эшләгән вакытта, эшләреннән канәгать булып, аннан тәм табып эшләгән әтиемне, андагы абыйларны күреп,аларга карап сокландым һәм горурландым. Киләсе елларда да әтием белән аның ярдәмчесе булып эшләрмен дип уйлыйм.

**Нәҗмиев Риназ, 5 класс укучысы**

**“Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен”...**

**Татар халык мәкале**

## Яхшылык

Маратларның күршесендә ялгыз карчык – Маһирә әби яши. Марат көн саен мәктәптән кайтканда аның өе яныннан үтә.



Беркөнне укудан кайтканда Марат Маһирә әбинең кар көрәгәнен күрде дә аны кызганып куйды. Төнне тагын бик күп кар яуды. Марат иртә торып, Маһирә әбинең капка төбен ялт итеп көрәп куйды. Күрше әби малайның эшләгән бу яхшылына рәхмәт әйтеп туя алмады.

**Хабибуллин Эмиль, 4 нче сыйныф.**




## Минем гаиләм.

Минем гаиләм – җылы оям ул. Безнең гаиләдә 4 кеше: әнием -Алия, апаларым Энҗе һәм Зөһрә, ә иң кечсе мин – Ралия.

Мин 2 нче сыйныфта укыйм. Яхшы укыйм шикелле, Римма апа укыта бит безне. Күп белемнәр бирә, тәртипкә, пөхтәлеккә өйрәтә.

Олы апаем Энҗе югары белемле юрист. Ул мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган. Белгечлек дипломында да бишлеләр генә.Ул миңа инглиз телен өйрәнергә булыша.

Зөһрә апаем төзүче булырга тели, быел ул техникумга укырга керде. Аның белән һәрвакытта да күңелле.

Минем гаиләм китаплы гаилә. Бездә тарихи һәм әдәби китаплар күп. Чөнки әтием дә, әнием дә укытучылар. Әтием мәрхүм инде.Ә әнием минем бик матур һәм ягымлы. Мин аны бик яратам.Уңышларым булса, әнемнең йөзе шатлыктан балкый, ә авырып китсәм, ул янымнан да китми дәвалый.

Минем әни күп эшләр эшли: тәмле ризыклар пешерә, матур гөлләр үстерә, машина йөртә. Бергә китаплар укырга, догалар өйрәтергә дә вакыт таба.

Без бик тату яшибез. Гаиләмне бик яратам.

**Садриева Ралия, 2 сыйныф укучысы**

## Безнең сыйныф

Мин инде 2 ел. Күәм урта мәктәбенең 7 нче сыйныфында белем алам. Яраткан фәннәрем дә бар: алгебра, рус теле һәм татар теле. Безнең сыйныф укучылары укытучыларны бик яраталар һәм хөрмәт итәләр. Белгәнебезчә: укытучыларның төп бурычы – безне укыту һәм яхшы кешеләр итеп тәрбияләү. Бу чыннан да шулай. Укытучыларыбыз бар көчләрен безне тәрбияләүгә куя.

Безнең сыйныфта 10 укучы укый. 5 малай һәм 5 кыз. Мин үзем староста ярдәмчесе булып торам.Төрле эшләрдә башлап йөрим һәм һәр эшне җиренә җиткереп эшләргә тырышам.

Безнең сыйныф җитәкчесе - Гөлнара Зөлкарь кызы. Ул – тарих һәм туган (татар) теле фәннәрен укыта. Ул һәрбер укучыны тыңлый һәм аңлый белә. Төрле кызыклы әйберләр белән таныштыра, өйрәтә һәм аңлата.

Безнең класста зур китапханә бар. Без аннан әдәби китаплар алып укыйбыз. Шигырьләр ятлаганда бу китапларны кулланабыз, рәсем ясаганда өлге итеп алабыз. Сыйныф кабинетын һәрчак чиста тотабыз. Чираттан дежур торабыз, уборкалар ясыйбыз, җиллләтәбез. Эле без тагын мәктәптә оештырылган төрле акцияләрдә, олимпиадаларда, бәйгеләрдә катнашабыз. Макулатура җыябыз, рәсемнәр ясыйбыз. Көнебезнең үткәнен сизми дә калабыз.

Мин үземнең мәктәбемне һәм дусларымны нык яратам. Мәктәптән чыгып киткәч тә, сагынырмын дип уйлыйм.

**Шакирова Камилә, 7 нче сыйныф укучысы**

## 2024 нче ел - Гаилә елы



Бу ел илебездә Гаилә елы дип игълан ителде. Телевизордан эмблемасы да күрсәтелеп тора. Эмблемада әти, әни, балалар сурәтләнгән булса да, минемчә, гаиләләр төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, әби яки бабай белән оныклар, әни белән балалар, әти белән балалар, ә кайбер очракларда балалар үзләре генә дә бер гаилә булып яшәргә мөмкиннәр. Ничек кенә булмасын, мондый гаиләләрнең дә гаилә булып аталырга һәм бәхетле булырга хаклары бар дип уйлыйм мин.

Дөньяда һәр кешенең үз юлы, үз сукмагы һәм үз язмышы. Алар бер-берсенә охшамаган. Тик шулай да араларында бер уртаклык бар: җир йөзенә без барыбыз да нәсел калдырырга, бәхетле булырга килгәнбез. Кеше исемен йөртүче затның бу тормышта якты эзе, матур эше калырга тиеш. Ә үзеңнең якты эзеңне калдыру өчен туган йортың, гаиләң булу кирәк. Гаилә — ул кешенең таяныр ноктасы. Безнең бәхет гаиләдә. Гаиләбез бар икән, димәк безнең киләчәгебез бар! Без бәхетле!

Биш хәрефтән генә торган гаилә сүзе бик зур мәгънәгә ия. Гаилә диюгә, безнең күз алдыбызга баш өстендәге түбә, бер үк фамилияләр, әти-әни һәм бу гаиләне дәвам итүче балалар килә. Гаилә, минемчә, бер-берсенә ярдәм итүче, яклаучы, саклаучы бер оя ул. Бу оядa кеше ял итә һәм үзен тыныч, рәхәт итеп тоя. Һәм һәр кешенең тормышы шушы оядан, гаиләдән башлана. Ә гаиләнең ныклыгы, әти-әнинең җылы мөнәсәбәте, әлбәттә, без, балалар белән бәйләнгән. Мин үземне бик бәхетле итеп тоям, чөнки минем яраткан кешеләрем, гаиләм бар.

Мин үз гаиләмне бик тә яратам. Алар да мине яраталар. Мин аларның һәрчак сау-сәламәт, озын гомерле, бәхетле булуларын теләп яшим. Бөтен-бөтен гаиләләргә дә иң изге теләкләремне телим. Мин бөтен кешеләрнең бер-берсенә изге теләктә булып яшәүләрен телим.

**Гатауллина Илүзә, 10 сыйныф укучысы**



**Кош канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле...**

**Татар халык мәкале**



## Авылым чишмәләре.

Чишмәләр – су чыганагы, ә су – тормыш чыганагы. Һавадан кала, су – кешенең иң кирәкле әйбере. Ашамыйча берничә ай йөреп булса, су эчмичә кеше 3 көннән артык тора алмый. Суга ихтыяҗ бик зур.


Минем туган авылымда өч чишмә бар. Аларның тирә-ягы һәрвакыт чистартылып тора. Сыер көтүе йөри торган юлда урнашканы Салкын чишмә дип атала. Узган ел аның киртәләрен һәм чишмә урнашкан бинасын яңарттылар. Хәзер бу чишмәерактан ук күренеп тора. Шәһәрдән кайткан авылдашларыбыз аның шифалы суын савытларга тутырып алып китәләр. Шулай итеп туган як, туган авылны чәй эчкән саен искә алалар, сагыналар һәм тагын әйләнеп кайталар.

Татар халкында чишмәләргә багышланган әсәрләр, шигырьләр, җырлар, мәкаль һәм әйтемнәр бик күп. Гомумән алганда, безнең халкыбыз – җырлы-моңлы халык. Шул чишмәнең челтерәп аккан тавышына кушылып, моң-зарларын җыр итеп җырлаган, бушанган. Татар халкы – тырыш, чисталык-пөхтәлек яратучы халык, үзенең тормыш чыганагы булган суны элек-электән данлаган, аңа булган хөрмәтен яшь буынга тапшырган.

Мин дә чишмәгә барырга бик яратам. Чишмә чыккан урын ящерен серләр саклыйдыр кебек. Җәй көне әбием белән чишмә буена төшеп аның тавышын тыңлыйбыз, кечкенә савытларга тутырып салкын суын чәйгә алып кайтабыз. Чишмәләрне сакларга, кадерләргә, һәрвакыт чиста-пөхтә тотарга кирәк.

**Халикова Фирүзә, 6 нчы сыйныф укучысы.**

## Балаларга - кроссворд




**Сораулар:**

***Вертикаль:***

1. Тәмле, тик алма түгел, Койрыклы, тычкан түгел. , 2. Ай белән килә, көн килгәч китә, 3. Тел өчен ул җавап бирә, 4. Агачка оя кормый, оясы — җирдә, җыры — күктә, 5. Өстәл янында иң кирәге нәрсә? 6. Җәрәхәте юк — авырта, төтене юк — яна.

***Горизонталь:*** 7. Җәй дә, кыш та бер төстә, 8. Агач башы тукылдык, тукый-тукый тук булдык, 9. Йомык күз белән дә күреп була, 10. Бит-кулларны корыта,чисталыкны ярата.

## Яхшылык җирдә ятмый

Яхшылык ул – изгелек , мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. Ярдәм итеп, кеше башкаларга бәхет һәм шатлык китерә. ”Яхшылык җирдә ятмый” дигән борынгылар. Чынлап та, яхшылык беркайчан да онытылмый. “Яхшы гадәт адәм итәр, начар гадәт әрәм итәр”, ди халык мәкале. Әйе, яхшылык эшләү кешегә файда китерә.

Яхшылыкны мин ак төстә күрәм. Ак ул - пакълык төсе. Яхшы гамәлләр эшләү, бик зур мактауга лаек. Аны үлчәүдә генә үлчәп булмый. Калган яхшы эшләр күңелдә, йөрәктә кала һәм кире үзенә яхшылык булып кайта. Әби – бабайларга, авыр хәлле кешеләргә булыштыңмы, өйдә эти – әниеңә, дустыңа ярдәм иттеңме, кемгә генә яхшылык эшләсәң дә, бу – изгелек.

Тормышта бер – береңә ярдәм итеп, изгелек кылып яшәргә кирәк. Бала кечкенәдән яхшылыкка омтылып үсә, аның күңеле изгелектә була.

**Галявиева Алия, 5 нче сыйныф укучысы**

## Күзгә матур эшләр....

Көз көне табигать үзенчә матур. Аеруча бу матурлыкны урманга баргач күрергә була. Агач яфраклары, әйтерсең җәй буена кояшта кызынып, күзгә таба алтын төсенә кергәннәр. Кояш нурларын сеңдереп авырайганнар да, саргаеп коела башлаганнар. Яшел, сары, ал, саргылт-кызыл, күгелҗем яфраклар үзара лепер-лепер килеп сөйләшәләр дә төсле. Өзелеп төшкәннәре урманның тирә-ягын чуар келәмгә әйләндереп, аяк астында шыгыр-шыгыр килеп нидер сөйлиләр дә сыман.
Көзге урман шул хәтле матур, сүзләр белән аңлатып та булмый. Бу искиткеч гүзәллекне үз күзләрең белән күрергә кирәк.

Мәктәбебез агачлар белән әйләндереп алынган. Матурлык – үзебезнең янәшәдә генә. Матурлыкны күрә белергә, эшли белергә генә кирәк. Мәктәптә төрле бәйрәмнәр, акцияләр үтә. Бу эшләрдә без дә катнашабыз. Башлангыч сыйныф укучыларының “Сөмбелә” бәйрәменә оештырылган күргәзмә бар укучыны үзенә җәлеп итте. Бик матур ясалган эшләрне карап күзләр камаша. Молодцы, башлангыч укучылары! Матур эшләр – матур башлангычлар ул!



**Исхаков Тимерхан, 7 нче сыйныф укучысы**

## Сынамышлар

Сентябрь аяз – кыш салкын.
Искечә беренче сентябрь күк күкрәсә, киләсе ел ашлык уңар, ләкин көз озак килер.